**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК СОВЕТЫ**
**АКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**IV ЧАКЫРЫЛЫШ**

**УНЫНЧЫ СЕССИЯ**

**КАРАР № 1**

т/юл ст. Акбаш п. 2021нче елның 24 июне

**Акбаш авыл җирлеге Советының 2020нче елның 14 нче февралендә узган 49 нчы сессиясенең 4 нче карары -“Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә”гә үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 02.03.2007 ел, № 25-ФЗ Федераль законга, муниципаль хезмәт турында 25.06.2013 ел, №50-ТРЗ Татарстан Республикасы кодексына туры китерү максатларында

**Акбаш авыл җирлеге Советы**
**Карар:**

1. «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә турында» Акбаш авыл җирлеге Советының 2020 елның 14 февралендәге 49нчы сессиясе карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 13 статьяда:

- 5 өлешне яңа редакциядә бәян итәргә:

5) җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын бетерү максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый.»

2.Әлеге карар Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә һәм басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

**Акбаш авыл җирлеге башлыгы Р.Т.Хуҗиев**